ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТУРИЗМУ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТУРИСТЛЫК БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

10.12.2018 Казан ш. № 152

Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының «Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитеты каршында Иҗтимагый совет турында нигезләмә раслау турында» 2015 елның 17 апрелендәге 44 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитеты каршында Иҗтимагый совет турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 18 ноябрендәге 906 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршындагы иҗтимагый совет турында бертип нигезләмәгә үзгәрешләр кертелүгә бәйле рәвештә, боерык бирәм:

Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының «Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитеты каршында Иҗтимагый совет турында нигезләмә раслау турында» 2015 елның 17 апрелендәге 44 номерлы боерыгы белән (Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының 2015 елның 1 декабрендәге 157 номерлы, 2016 елның 7 июнендәге 49 номерлы, 2017 елның 30 октябрендәге 188 номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитеты каршында Иҗтимагый совет турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1 пунктта дүртенче абзацны көчен югалткан дип танырга;

3.2 пунктта «аның составында 14 кеше» сүзләрен «аның составында 16 кеше» сүзләренә алмаштырырга;

5.4 пунктта өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Иҗтимагый совет карарлары тавышларның гадәти күпчелеге нигезендә кабул ителә. Тавышлар саны тигез булганда, Иҗтимагый совет утырышына рәислек итүче затның тавышы хәл иткеч була.»;

5.12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.12. Иҗтимагый совет карары нигезендә, Иҗтимагый совет утырышларына Иҗтимагый советта каралучы мәсьәләләр буенча кирәкле белешмәләрне һәм бәяләмәләрне бирү өчен башкарма органнарның, коммерциясез оешмаларның, фәнни учреждениеләрнең вәкилләре, экспертлар, башка белгечләр һәм гражданнар чакырылырга мөмкин.

Иҗтимагый совет әгъзалары булып тормаган массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре Иҗтимагый совет чакыруы буенча Иҗтимагый совет утырышларында катнашырга мөмкин.».

Рәис С.Е. Иванов